**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИ-ПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИ-ТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ 05.09.2024 № ПР-157 КАРАР № ______

**Район хәрби хезмәткә чакырылучылар көнен үткәрү турында**

Актаныш муниципаль районында яшьләргә патриотик тәрбия бирү эшенең нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Хәрби комиссариатка Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының социаль һәм агарту эшләре бүлеге белән берлектә хәрби хезмәткә чакырылучылар көнен 2024 елның 25 октябрендә үткәрергә. Район хәрби хезмәткә чакырылучылар көнен үткәрү планын 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Актаныш муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына хәрби хезмәткә чакырылучыларның һәм аларның ата-аналарының 2024 елның 25 октябрендә әлеге чарага килүләрен тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
3. Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына хәрби комиссариатка 2024 елның көзендә чакырылырга тиешле хәрби хезмәткә чакырылучыларга бүләкләр алу өчен 10000.00 сум күләмендә акча бүлеп бирергә, 2 нче кушымта нигезендә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
_________ 2024 ел, №____
2 нче кушымта

**Район хәрби хезмәткә чакырылучылар көнен уздыру планы**

| № т/б | Чараларның атамасы | Үткәрү вакыты | Җаваплы | Урнашкан урыны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Хәрби хезмәткә чакырылучыларга һәм аларның ата-аналарына хәбәр итү һәм җыю | 9:00 25.10.2024 ел | Актаныш районы хәрби комиссариаты, авыл җирлекләре башлыклары | «Яшьлек» мәйданы |
| 2. | Җыелу | | | |
| | • хәрби хезмәткә чакырылуга һәм хәрби хезмәт үтүгә бәйле Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Конституциясе статьяларын җиткерү буенча чакырылыш комиссиясе рәисе чыгышы; | 9:00 – 9:15 | чакырылыш комиссиясе рәисе | «Яшьлек» мәйданы |
| | • «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» РФ законын аңлату белән Татарстан Республикасы хәрби комиссариат бүлеге башлыгы чыгышы; | 9:15 – 9:30 | Актаныш районы хәрби комиссары | «Яшьлек» мәйданы |
| | •«Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның җаваплылыгы» темасына район прокуроры чыгышы; | 9:30 – 9:45 | район прокуроры | «Яшьлек» мәйданы |
| | • хәрби хезмәткә чакырылу контингентының сәламәтлегe торышы мәсьәләсе буенча өлкән табибның чыгышы; | 9:45 – 10:00 | өлкән табиб | «Яшьлек» мәйданы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | • Бөек Ватан сугышында катнашучылар, сугышчы-интернационалистларның чыгышлары һәм башкалар. | 10:00 – 10:15 | | «Яшьлек» мәйданы |
| | • армиягә чакырылучыларның һәм аларның ата-аналарының теләкләре | 10:15 – 10:30 | | «Яшьлек» мәйданы |
| | • Катнашучыларда барлыкка килгән сорауларны ачыклау | 10:30 – 10:45 | | «Яшьлек» мәйданы |
| 3. | Үзешчән сәнгать концерты | 10:45 – 11:15 | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының социаль һәм агарту эшләре бүлеге башлыгы; | «Яшьлек» мәйданы |
| 4. | Тәнәфес | 11:15 – 11:30 | | |
| 5. | Бүләкләр тапшыру белән спорт ярышлары | 11: 30 | яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы | Балалар иҗат йорты |

*Игътибар: Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә турыдан-туры буйсынмаган җаваплы затлар хәрби хезмәткә алынучы көнен килешү буенча уздыру планына кертелә.

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
_________ 2024 ел, №____
2 нче кушымта

**ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘ ЧАКЫРЫЛУЧЫЛАР КӨНЕН ҮТКӘРҮГӘ ЧЫГЫМНАР СМЕТАСЫ**

| № т/б | Чыгымнарның исеме | Сумма |
|---|---|---|
| **1** | Приз фонды (ату, йөгерү, гер күтәрү, күтәрелү, АКМ җыю)<br>1 урын-300 сум х 5 кеше - 1.500 сум<br>2 урын-250 сум х 5 кеше - 1.250 сум<br>3 урын-200 сум х 5 кеше - 1.000 сум | 7000 сум |
| **2** | Грамоталар - 30 сум х 18 кеше - 180 сум | 1000 сум |
| **3** | Блокнот һәм ручка 40 сум х 47 кеше = 1880 сум | 2000 сум |
| **4** | **Барлыгы:** | **10000 сум** |